КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1526

2024 елга социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасында авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен төзү һәм раслау һәм авыл территорияләрендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү тәртибенең 19 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга Татарстан Республикасында авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасында авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 31,8 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2020 елга социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында» 2019 ел, 16 декабрь, 1153 нче;

«2021 елга социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында» 2021 ел, 24 март, 162 нче;

«2022 елга социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында» 2022 ел, 09 февраль, 103 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин